# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ
# СОВЕТЫ

## КАРАР

**№ 15** **Урыссу ш.т.п.** "15" 11 2022

**Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында» 07.05.2014 ел, №5 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 маддәсе, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 19.08.2010 ел, №ЯК-7-8/393@ Боерыгының 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 07.05.2014 ел № 5 карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1 пунктта:

Түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

"- балалар йортларында һәм приютларда тәрбияләнүче, ата-аналары ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән балигъ булмаганнарга карата җир салымы һәм физик затлар милкенә салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча;

- Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында (ЕГРЮЛ) мәгълүмат булмаган юридик затларга карата җир салымы буенча;

- аны түләтү срогы чыкканнан соң, юридик затларның пенялар буенча бурычлары булу, аларга өстәлгән недоимка булмаганда».

2. Әлеге карар бурыч барлыкка килгәннән соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, hpps://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башлыгы -
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин